**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Коморгузинского сельского поселения Атнинского муниципального района**
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана, зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл жирлеге Советы**
422758, Комыргужа авылы, Татарстан урамы., 40Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2024 ел. № 8

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 16 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 16 ноябрь 2024 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны — Мәрҗән авылы, М.Җәлил урамы, 11 йорт, Мәрҗән авыл клубы залы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 09 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт;
- сайлау хокукына ия булган Мәрҗән торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Мәрҗән торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Мәрҗән авылы территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Мәрҗән авылындагы үләннәрне чабу).
2) Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (Мәрҗән авылындагы зират территориясен чистарту (үлән чабу, агач кисү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40 йорт, Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Т.Гатауллин